**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «12» февраленнән № 58

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 25 сентябрендәге 406 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 25 сентябрендәге 406 нчы карарына (Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 17 гыйнварындагы 15 номерлы, 2014 елның 31 мартындагы 128 номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 299 номерлы, 2016 елның 11 маендагы 187 номерлы, 2017 елның 14 февралендәге 84 номерлы, 2017 елның 25 августындагы 425 номерлы, 2018 елның 19 гыйнварындагы 25 номерлы, 2019 елның 16 сентябрендәге 230 номерлы, 2020 елның 04 апрелендәге 94 номерлы 2021 елның 03 февралендәге 46 номерлы, 2021 елның 31 мартындагы 159 номерлы, 2023 елның 15 мартындагы 66 номерлы карарлары керткән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 25 сентябрендәге 406 нчы карарының (Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 августындагы 425 номерлы карары керткән үзгәрешләр белән) түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«7. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә һәм Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа операторы билгеләгән форматлар нигезендә урнаштырыла.».

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 25 сентябрендәге 406 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 25 августындагы 425 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов